| | | |
|---|---|---|
| МИНИСТЕРСТВО<br>СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА<br>И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ<br>ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК<br>МИНИСТРЛЫГЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

01.09.2015 г.Казань № 205/2-пр

**Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының "2015 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында" 2015 елның 15 гыйнварындагы 3/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең "Крестьян (фермер) хуҗалыкларының, индивидуаль эшкуарларны да кертеп, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә караган алар тарафыннан файдаланыла торган җир кишәрлекләрен милек буларак рәсмиләштергәндәге чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына федераль бюджеттан субсидияләр бирү һәм бүлү кагыйдәләрен раслау турында" 2011 елның 31 октябрендәге 874 номерлы карарын үтәү максатында

**б о е р ы к б и р ә м:**

1. Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының "2015 елга Татарстан Республикасының агросәнәгать комплексына дәүләт ярдәме өчен федераль бюджеттан килә торган акчалар исәбеннән субсидияләр бирү тәртипләрен раслау турында" 2015 елның 15 гыйнварындагы 3/2-пр номерлы боерыгына (алга таба – Боерык) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Боерыкның 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле пунктча өстәргә:

"1.11. Крестьян (фермер) хуҗалыкларының, индивидуаль эшкуарларны да кертеп, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә караган алар тарафыннан файдаланыла торган җир кишәрлекләрен милек буларак рәсмиләштергәндәге чыгымнарының бер өлешен каплау өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән 2015 елда субсидияләр бирү тәртибе (11 нче кушымта)".

2. Боерыкка 11 нче кушымтаны әлеге Боерыкка кушымтада каралган редакциядә бәян итәргә;

3. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасарлары Н.Л. Титовка йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

2015 елның 1 сентябрендәге 205/2-пр номерлы
ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгына
кушымта

2015 елның 15 гыйнварындагы 3/2-пр номерлы
ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
министрлыгы боерыгына
11 нче кушымта

Крестьян (фермер) хуҗалыкларының, индивидуаль эшкуарларны да кертеп, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә караган алар тарафыннан файдаланыла торган җир кишәрлекләрен милек буларак рәсмиләштергәндәге чыгымнарының бер өлешен каплау өчен федераль бюджет акчалары исәбеннән
2015 елда субсидияләр бирү
тәртибе

1. Әлеге Тәртип крестьян (фермер) хуҗалыкларының, индивидуаль эшкуарларны да кертеп, авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә караган алар тарафыннан файдаланыла торган җир кишәрлекләрен (алга таба – җир кишәрлекләре) милек буларак рәсмиләштергәндәге чыгымнарының бер өлешен каплау өчен 2015 елда субсидияләр (алга таба – субсидияләр, КФХ) бирү механизмын билгели.

2. Субсидияләр Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә караган КФХ тарафыннан файдаланыла торган җир кишәрлекләрен милек буларак рәсмиләштергәндә кадастр эшләрен үткәрүгә түбәндәге очракларда бирелә:

КФХна милек, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалану, мирас итеп калдырыла торган гомерлекчә хуҗалык яки сатып алу хокукы белән арендалау хокукларында бирелгән җир кишәрлекләренең чикләре урнашу урыннарын төгәлләштергәндә;

җир кишәрлекләрен милек хокукында һәм ахырда сатып алу хокукы белән арендалау хокукында КФХна караган җир өлешләренә кертеп төзегәндә.

3. Җир кишәрлекләренә милек хокукы һәм әлеге Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән башка хокуклар билгеләнгән тәртиптә Күчемсез мөлкәткә хокукларның һәм алар белән алыш-бирешләрнең бердәм дәүләт реестрында теркәлгән булырга тиеш.

4. Субсидияләр КФХ дәүләт теркәвенә алынган булса һәм алар җитештерү эшчәнлекләрен Татарстан Республикасы территориясендә башкарган очракта бирелә.

Ябылу стадиясендәге яки бөлгенлеккә (банкротлыкка) чыккан дип танылган КФХна субсидияләр бирелми.

5. КФХна субсидияләр алар тарафыннан милек буларак рәсмиләштерелгән җир кишәрлекләренең бер гектарына 393 сум исәбеннән Россия Федерациясе бюджеты акчаларыннан бирелә.

6. Субсидияләр алу өчен КФХ Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы министрлыгының (алга таба – Министрлык) Татарстан Республикасы муниципаль районында авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсенә (алга таба – Идарә), түләү реквизитларын һәм почта адресын күрсәтеп, субсидияләр бирү соралган гаризаны, шулай ук түбәндәге төп нөсхәләрне һәм күчермәләрне тапшыра (чагыштырып тикшергәннән соң, төп нөсхәләр гариза бирүчегә кире кайтарыла, ә күчермәләр документларны кабул итүне башкаручы зат тарафыннан таныклана):

физик затны индивидуаль эшкуар буларак дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкның яки крестьян (фермер) хуҗалыгын дәүләт теркәвенә алу турындагы таныклыкның;

кадастр эшләрен башкаруга шартнамәнең;

кадастр эшләрен башкару актының;

кадастр эшләрен башкарган өчен түләү фактын раслый торган түләү документының банк тарафыннан расланган күчермәсен;

җир кишәрлегенең кадастр паспортының;

җир кишәрлегенә милек хокукын теркәү турында таныклыкның.

7. Идарә:

а) субсидияләр бирү турындагы гаризаларны алар кергән көнне үк журналга теркәп куя, ул номерлана, шнурлана һәм аңа мөһер сугыла;

б) әлеге Тәртипнең 6 пункты нигезендә тапшырылган документларны карый. Документлар гаризаны теркәгән көнән соң 10 көн эчендә карала;

в) күрсәтелгән документлар нигезендә Министрлык тарафыннан расланган форма буенча Татарстан Республикасы муниципаль районы буенча субсидияләр бирүгә җыелма исәп-хисап белешмәләрен төзи һәм Министрлыкка тапшыра;

Субсидияләр бирүдә түбәндәге очракларда баш тартыла:

тулы булмаган документлар комплекты тапшырылса;

КФХ әлеге Тәртип шартларына туры килмәсә;

бюджет йөкләмәләре лимитлары булмаса.

Субсидияләр бирүдән баш тартуга шикаять Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә агымдагы ел дәвамында бирелә.

8. Министрлык бюджет акчаларын төп бүлүче булып тора һәм бюджет акчаларын Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган хосусый счетыннан Идарәләрнең Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль бүлекләрендә ачылган хосусый счетларына күчерә.

Субсидияләр күчерү өчен нигез булып Идарә тарафыннан Министрлыкка тапшырылган җыелма исәп-хисабка нигезләнеп башкарыла. Идарәләр үзләренең хосусый счетларына бюджет акчалары килгән көннән алып унбиш эш көне эчендә субсидияләрне КФХ исәп-хисап счетларына күчерә.

9. Алынган субсидияләр, аларны бирүнең әлеге Тәртиптә билгеләнгән максатлары һәм шартлары бозылу, субсидияләрнең максатчан билгеләнеше буенча файдаланмавы һәм (яки) дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырылу очраклары билгеле булганнан соң, Идарәнең тиешле таләбен алган көннән башлап алтмыш көн эчендә Россия Федерациясе бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

10. Хисап финанс елында файдаланылмый калган субсидияләр хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр Россия Федерациясе бюджеты керемнәренә субсидияләр алучылар тарафыннан кире кайтарылырга тиеш.

11. Күрсәтелгән акчаларны федераль бюджетка үз ихтыяры белән кайтарудан баш тартылган очракта, алар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә мәҗбүри рәвештә кире кайтарылырга тиеш.

12. Министрлык һәм (яки) дәүләт (муниципаль) финанс контроле органнары КФХна субсидияләр бирү шартлары, максатлары һәм тәртибе үтәлешен законнарда билгеләнгән тәртиптә тикшерә.

13. Министрлыкка Идарә тарафыннан һәм КФХ тарафыннан тапшырыла торган документларның дөреслеге өчен җаваплылык законнар нигезендә шул ук тәртип буенча аларның вазыйфаи затларына һәм җитәкчеләренә йөкләнә.

14. Бюджет акчаларының максатка ярашлы кулланылышын Министрлык тикшереп тора.